КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 17 апрель г.Казань № 481

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивален үткәрү турында» 2016 ел, 9 июнь, 386 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивален үткәрү турында» 2016 ел, 9 июнь, 386 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 14 июнь, 485 нче; 2018 ел, 24 август, 697 нче; 2019 ел, 19 апрель, 309 нчы; 2019 ел, 15 май, 394 нче; 2019 ел, 20 декабрь, 1177 нче; 2020 ел, 6 март, 179 нчы; 2020 ел, 21 сентябрь, 849 нчы; 2021 ел, 13 апрель, 244 нче; 2021 ел, 6 октябрь, 956 нчы; 2022 ел, 25 март, 271 нче; 2022 ел, 29 июль, 731 нче; 2022 ел, 6 октябрь, 1075 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивале турындагы нигезләмәнең 8.3 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты Кубогы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Кубогы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивален әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составында:

оештыру комитеты составыннан М.Р.Хисамиевны, Г.Р.Шакированы чыгарырга;

оештыру комитеты составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры Ринат Наил улы Садыйковны;

Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе урынбасары – Гражданлык җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлек итү идарәсе башлыгы Илнур Ирек улы Шакировны (килешү буенча);

Алексей Михайлович Пахомовның вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе) генераль директоры (килешү буенча)»;

Тимур Җәүдәт улы Сөләймановның вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе, Татарстан Республикасының Балалар һәм яшьләр гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәтенең төбәк бүлеге советы рәисе (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин